УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Федосеевская, 36, г. Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ
Федосеев ур., 36, Казан шәһәре, 420111

Телефон, факс (843) 221-77-85, сайт: www.gtn.tatarstan.ru, эл.почта: gostehnadzorrt@mail.ru

ПРИКАЗ　　　　БОЕРЫК

«09» декабрь 2020ел.　　　　№ 01/05/190-пр

Казан шәһәре

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе турында» 2011 елның 26 декабрендәге 1064 номерлы карарлары нигезендә,

боерык бирәм:

1. Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2018 елның 16 июлендәге 01-05/177-пр номерлы, «Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2018 елның 16 июлендәге 01-05/177-пр номерлы боерыгы белән расланган Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 7 декабрендәге 01-05/328-пр номерлы боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Теркәү, автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу һәм махсус эш секторына әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталында Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе сайтында, «Документлар» бүлегенең «Административ регламентлар» бүлекчәсендә урнаштырырга.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче Р.Р.Зыятдинов

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 09.12.2020 № 01-05/190-пр боерыгы белән расланды

**Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – дәүләт хезмәте, Регламент) сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: юридик затлар яки физик затлар.

Мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә закон нигезендә яки билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкил мөрәҗәгать итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Идарә), Идарәнең территориаль бүлекләре (алга таба – Идарә бүлеге, баш дәүләт инженер-инспекторы, вазыйфаи зат) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Идарә урнашкан урын: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев урамы, 36 йорт.

Идарәнең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, җомга: 8.00 сәгатьтән 15.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында «Батурин» тукталышына кадәр килергә кирәк:

- 22, 28, 89 номерлы автобуслар.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Идарә һәм Идарә бүлекләренең эш сәгатьләрендә, көн саен.

1.3.2. Идарә телефоннары: 8 (843) 221-77-85, 221-77-89.

Факс: 8 (843) 221-77-85.

1.3.3. Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://gtn.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алучы, һәм Идарә бүлекләренең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Идарәнең рәсми сайтында (http://gtn.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru);

3) Идарәгә һәм Идарә бүлекләренә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) Идарәгә һәм Идарә бүлекләренә язмача (шул исәптән электрон документ формасында да) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Идарәнең, Идарә бүлекләренең урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Идарәнең электрон почта адресы турында мәгълүмат Идарәнең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Идарәнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» челтәрендә Идарәнең рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчасында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Идарәнең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәгъваларны карау акты – мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатен карау нәтиҗәсендә бирелә торган документ;

ДМТ ДМС – дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы;

Дәүләт техник күзәтчелек эксперты – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең тракторларны һәм башка үзйөрешле техниканы исәпкә алу буенча программа тәэминаты;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны (алга таба – күпфункцияле үзәк) – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган

күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон)). Гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Күзәтчелектәге машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының сатылган яки төзекләндерелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавы турындагы дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу (алга таба – дәүләт хезмәте). | Министрлар Советы – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында» 1993 елның 13 декабрендәге 1291 номерлы карарының (алга таба – 1291 номерлы карар) 5 пункты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1064 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына |

| | | |
|---|---|---|
| | | күзәтчелек идарәсе турындагы нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 4.1 пункты |
| 2.2.Башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе һәм Идарә бүлекләре | Нигезләмә |
| 2.3.Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Төп нәтиҗәләр, техниканы торгызу чыгымнары, чыгымнарны түләү өчен җаваплы як, җитештерүче предприятие (тәэминатчы) тарафыннан китертелергә тиешле детальләр, төеннәр һәм агрегатлар номенклатурасы булган дәгъваны карау акты. Акт өч нөсхәдә төзелә.<br>Дәгъваны карау актының дубликаты. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | Дәүләт хезмәте гариза һәм документлар теркәлгәннән соң 7 эш көне эчендә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны тапшыру үзйөрешле техникага яки җайланмага тикшерү уздырылган көнне гамәлгә ашырыла.<br>Дәгъваны карау актының дубликатын бирү гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар | 1) дәгъваны карау турында гариза; | |

| | | |
|---|---|---|
| нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 2) мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ;<br>3) машина хуҗасы вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы ышаныч кәгазе яисә башка төрле документ (машина хуҗасы вәкиле өчен);<br>4) үзйөрешле машинаның паспорты яки машина милекчелек хокукын раслаучы башка төрле документлар.<br>5) гарантия талоны белән сервис кенәгәсе.<br>6) товар накладнаясы.<br>7) эксплуатация документлары (эксплуатацияләү буенча күрсәтмә, эксплуатация буенча кулланма, техник хезмәт күрсәтү буенча күрсәтмә).<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Идарәнең рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән яки почта аша.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, | 1.Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | идарәсендә) (электрон рәвештә формалаштырылганы Россия Федераль салым хезмәте сайтында).<br>2.Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсендә).<br>3. Дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр һәм/яки Дәүләт техник күзәтчелек хезмәтләре өчен түләү турында белешмәләр (Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсе, Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе).<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче мәртәбә баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1.Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Тапшырылган документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм алдан әйтелмәгән башка, шулай ук карандаш белән ясалган, төзәтмәләр булуы. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>– дәүләт хезмәте күрсәткән өчен җыем түләү турында мәгълүмат булмавы;<br>– үзйөрешле техниканың һәм җайланманың тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәве;<br>– эксплуатацияләү буенча гарантия срогының тәмамлануы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә хезмәт күрсәткән өчен җыем күләме 237 сум тәшкил итә. | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төрле |

| | | |
|---|---|---|
| | | машиналарның һәм аларга тагылма арбаларның техник торышына, шулай ук агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләренең үтәлешенә дәүләт күзәтчелеген үткәргәндә хезмәтләр күрсәтү өчен җыемнар күләмен билгеләү хакында» 2016 елның 23 декабрендәге 7-22/т номерлы карары (алга таба – 7-22/т номерлы карар) |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтүгә документлар тапшыру чират булганда – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гаризаны һәм документларны тапшырган көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Татарстан Республикасы Министрлар |

| | | |
|---|---|---|
| стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Катнашу урыны Татарстан Республикасы Телекоммуникацияләрнең дәүләт интеграция системасына тоташтырылган электрон мәгълүмат киоскы (инфомат) белән җиһазландырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, объектлардан һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу шартлары;<br>объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу, шулай ук мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга объектларда ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>хезмәттән файдалану өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н | Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.<br>2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:<br>Идарә биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Идарәнең рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Идарә белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле | |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (алга таба – комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә дә) мөмкинлеге яки аннан файдалана алмау | шикаятьләрнең булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Идарә белгечләре белән бәйләнешкә керү күләме;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда, турыдан-туры – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Бүлек белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://www.gtn.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан http://www.uslugi.tatarstan.ru алынырга мөмкин.<br>Идарәдә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле рәсми мөрәҗәгатьләрне, документларны, мәгълүматны тапшыру, шулай ук мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алу Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә, мөрәҗәгать итүченең яшәгән яки физик затларның торган урынына бәйсез рәвештә, Идарәнең мондый хезмәтләрне күрсәтә торган теләсә кайсы структур бүлекчәсендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша күрсәтелми.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештә гаризаны, алга таба документларның төп нөсхәләрен тапшыру юлы белән, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеге бар. | «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон, 210-ФЗ номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган башка таләпләр | | Федераль закон |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү;

тапшырылган документларны тикшерү;

ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

комиссия тарафыннан үзйөрешле машинаны яки җайланманы карау;

дәгъваны карау актын төзү һәм имзалау;

техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша Идарәгә һәм/яки Идарә бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Идарә һәм/яисә Идарә бүлекләре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә.

Бланкны тутырганда зарурлык булганда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы һәм техник карау үткәрүнең башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Тапшырылган документларны тикшерү.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән кәгазьдә яисә электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша Идарә бүлегенә, әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны теркәп, сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешсез сыйфатына бәйле рәвештә дәгъваны карау турында гариза тапшырыла.

Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

документларны кабул итә;

документларны әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә җавап бирү-бирмәве предметына тикшерә;

Документларны кабул итүдән баш тарту буенча әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, баш дәүләт инженер-инспекторы мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү буенча каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документны кайтарып бирү сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кайтарып бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза һәм документларны кабул итү яки документларны кабул итүдән баш тарту.

3.4. Ведомствоара электрон мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Тапшырылган документларны тикшергәннән соң баш дәүләт инженер-инспекторы ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр бирү турында Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә;

Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсеннән Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә җыем түләү турында белешмәләр бирү турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт органнарына ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр, законнарда билгеләнгән чорда, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә бүлегенә җибәрелгән, рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган документлар, белешмәләр.

3.5. Комиссия тарафыннан үзйөрешле машинаны яки җайланманы карау.

3.5.1. Әлеге Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән белешмәләр алынгач, Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан үзйөрешле техниканы һәм җайланмаларны тикшерүдә катнашу турында карар кабул ителә.

Баш дәүләт инженер-инспекторы, машинаның хуҗасы һәм тәэмин итүче предприятие (әзерләүче яки сервис оешмасы) вәкиле катнашында гарантияле, аварияле техниканы карау эше башкарыла.

Техниканы караганнан соң баш тарту сәбәбе, гаепле як, торгызу өчен кирәкле төеннәр һәм детальләр, торгызу бәясе һәм эшсез торган вакытны исәпкә алып, китерелгән гомуми зыян күләме ачыклана.

Дәгъваны карау нәтиҗәләре буенча Дәгъваны карау акты төзелә.

Идарә вәкиле үз ягыннан Дәгъваны карау актына имза сала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәгъваны карау турында Идарә вәкиле тарафыннан имзаланган акт.

3.6. Дәгъваны карау акты өч нөсхәдә төзелә һәм мөрәҗәгать итүчегә, Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторына, тәэмин итүче предприятие (әзерләүче яки сервис оешмасы) вәкиленә техникадан баш тартуларны исәпкә алу журналында имза куйдыртып бирелә.

Әлеге Регламентның 3.5-3.6 пунктларында билгеләнә торган процедуралар карауны уздыру көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәгъваны карау турында тапшырылган акт.

3.7. Дәгъваны карау актын югалткан яки бозган очракта, тиешле дубликат Идарәнең күрсәтелгән актны рәсмиләштергән бүлеге тарафыннан үзйөрешле техника хуҗасының яки җайланманың хуҗасы яки аның вәкиле гаризасы нигезендә бирелә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән кәгазьдә яисә электрон формада Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша югалган яисә бозылган Дәгъваны карау актына алмаш итеп дубликат бирү турында гариза тапшырыла.

Югалган яки бозылган Дәгъваны карау актына алмаш итеп дубликат бирү гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

Баш дәүләт инженер-инспекторы мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән документның әзер булуы турында хәбәр итә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәгъваны карау актының дубликатын бирү.

3.8. техник хаталарны төзәтү.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән кәгазьдә яисә электрон формада Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән техник хаталарны бетерү турында гариза тапшырыла.

Үзгәртеп рәсмиләштерү эше мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан бирелгән, техник хаталары булган документны теркәп теркәүгә алынган гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

Баш дәүләт инженер-инспекторы:

техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында терки;

машина турында белешмәләрне автоматлаштырылган исәпкә алу системасына кертә;

техник хаталар булган документны үзгәртеп рәсмиләштерә.

Баш дәүләт инженер-инспекторы мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән үзгәртеп рәсмиләштерелгән документ турында хәбәр итә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән документ.

3.9. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору Идарә җитәкчесе, Идарә бүлегендәге вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Идарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Идарә бүлекләре турындагы нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (Регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1' өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Идарә, Идарә бүлекләре хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Идарә бүлеге хезмәткәрләре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Идарәнең бүлек җитәкчесенә бирелә.

Идарә бүлеге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Идарәгә тапшырыла.

Идарә җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органдагы вазыйфаи зат, дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Идарәнең http://gtn.tatarstan.ru рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләренраслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять

белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗасы дәгъвасын карауда катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

Дәүләт техник күзәтчелек бүлеге җитәкчесенә
____________________________________________

Баш дәүләт инженер-инспекторга ____________________________________

Кем-нән ________________________________________________________

(милекченең фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), оешманың тулы атамасы)

Салым түләүче-нең тәңгәл-лек номеры: ________________________________________________________

Адрес: ________________________________________________________

(физик затның яшәү урыны буенча адресы, юридик затның урнашкан урыны буенча адресы)

Телефон: ________________________________________________________

**Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗасы дәгъвасын карап тикшерүдә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә**

**ГАРИЗА**

Үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗасының сатылган яисә төзекләндерелгән техниканың тиешсез сыйфатына бәйле дәгъвасын карауда катнашуны сорыйм

| № | Үзйөрешле машинаның аталышы, маркасы | Дәүләт теркәвенә алу тамгасы | Рамасының завод куйган номеры | Двигатель номеры |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |
| 5 | | | | |

________ сум күләмендә дәүләт техник күзәтчелек хезмәтләре өчен түләү турында 20___ елның «__» ____________ № ____ квитанция.

**Тикшерү уздыру турында мәгълүмат**

*Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутырыла:*

Үзйөрешле техниканы һәм җайланманы
түбәндәге адрес буенча карауны сорыйм: ______________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Тикшерү үткәрү датасы:
__________________________________________________________________

Үзйөрешле техниканы һәм җайланманы карап чыгу түбәндәгеләргә ышанып тапшырыла:
________________________________________________
________________________________________________

______________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), ышаныч кәгазе, элемтә өчен телефон)

______________________________________________________________________

Дата «___» _____________ 20___ ел

Мөрәҗәгать итүченең имзасы,
(предприятие җитәкчесе урынбасары): ____________ _______________________
Мөһер урыны (фамилия, инициаллар)
булган очракта

**Гаризаны кабул итү турында тамга**

Дата: «____»___________ 20____ ел.

Дәүләт техник күзәтчелек инженер-инспекторы: ________________________________
Имза:_______________

Тикшерү уздыруның килештерелгән датасы һәм вакыты:
________________________________________

Үзйөрешле
техниканы һәм
җайланманы
карауны Дәүләт ___________________________ _______________

техник күзәтчелек
идарәсенең дәүләт
инженер-
инспекторы
уздырды:

(имза) (фамилия, инициаллар)

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗасы дәгъвасын карауда катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең ________________________________
бүлеге җитәкчесе -
Баш дәүләт инженер-инспекторына
_____________________________________________________________________
Кемнән _______________________________________________________________
(милекченең фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), оешманың тулы атамасы)
Салым түләүченең тәңгәллек номеры:__________________________________________
Адрес:________________________________________________________________
(физик затның яшәү урыны буенча адресы, юридик затның урнашкан урыны буенча адресы)
_____________________________________________________________________
Телефон:______________________________________________________________

**ГАРИЗА**

Баш дәүләт инженер-инспекторы җибәргән техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яисә арифметик хатаны) бетерүегез турында үтенәм:

| № | Үзйөрешле машинаның аталышы, маркасы | Дәүләт теркәвенә алу тамгасы | Рамасының завод куйган номеры | Двигатель номеры |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |

Дата: «___» ___________ 20___ел.

Мөрәҗәгать итүченең имзасы,
(предприятие җитәкчесе урынбасары): ____________ ________________________
(фамилия, инициаллар)

**Гаризаны кабул итү турында тамга**

Дата: «___» ___________ 20___ел.

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе дәүләт инженер-инспекторы:______________________________

(фамилия, инициаллар)

Имза:_________________________

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗасы дәгъвасын карауда катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

# ДӘГЪВАЛАРНЫ КАРАУ АКТЫ

Акт төзелгән урын

______________________________________________

хуҗа, физик зат вәкиленең, вәкилнең (юридик зат) фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), почта адресы

______________________________________________

Түбәндәгеләр составындагы комиссия тарафыннан төзелде:

тәэмин итүче (әзерләүче) предприятие вәкиле: ______________________

______________________________________________

фамилия, исем, ата исеме (булган очракта), вазыйфа

Дәүләт техник күзәтчелек инспекциясе вәкиле ______________________

______________________________________________

фамилия, исем, ата исеме (булган очракта), вазыйфа

хуҗа вәкиле ______________________

фамилия, исем, ата исеме (булган очракта), вазыйфа

машинага яки җайланмага ______________________

Марка-сы ______________________ **төзәтү датасы** ______________________

эксплуатациягә кертү датасы (сатканнан соң, төзәткәннән соң) ______________________

Тәэмин итүче предприятие (әзерләүче, сервис оешмасы)

завод номеры

двигателенең номеры

эксплуатациягә керткән вакыттан башлап машина эшләгән

сәгать (көн)

Эшләгәндә

эшләр төрен күрсәтергә

Машинаның яки җайланманың төзексезлеге түбәндәгедә чагылды

*Эксплуатация кагыйдәләрен бозулар ачыкланды*

Комиссия нәтиҗәсе

Машинаны яки җайланманы торгызу чыгымнары түләнергә тиеш

Машинаны яки җайланманы торгызу өчен түбәндәге агрегатларны (төеннәрне, детальләрне) алмаштырырга кирәк

агрегатларның (төеннәрнең, детальләрнең) аталышы, каталог буенча №ы

Тәэмин итүче предприятие (әзерләүче) түбәндәге адреска китерергә тиеш

түбәндәге агрегатларны (төеннәрне, детальләрне)

| | |
|---|---|
| Тәэмин итүче предприятие (әзерләүче, сервис оешмасы) вәкиле | Хуҗа вәкиле |
| «_____»___________20__ ел. _________________ имза | «_____»___________20__ ел. _________________ имза |
| Дәүләт техник күзәтчелек инспекциясе вәкиле | Комиссиянең башка вәкилләре |
| «_____»___________20__ ел. _________________ имза | «_____»___________20__ ел. _________________ имза |

Машинаны яки җайланманы торгызу эшләре _______________ (дата) төгәлләнде

Төзәтелгән машина яки җайланма хуҗасына ________________ (дата) кайтарып бирелде

Тәэмин итүче (әзерләүче, сервис оешмасы) вәкиле

_______________________________________

имза

Хуҗа вәкиле

________________________________________

имза

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗасы дәгъвасын карауда катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары.

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе.

| Вазыйфа | Телефон | электрон адресы |
|---|---|---|
| Идарә җитәкчесе | 221-77-85 | gostehnadzorrt@mail.ru |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе җитәкчесе | 264-77-15 | prav@tatar.ru |